Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл жирлеге составына керүче Олы Елга авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

18 ноябрь 2022 ел №8

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Олы Елга авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче төркем инвалидлардан мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре), 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә:

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

-торак пунктлар чикләрендә урамнарны яктырту челтәрләрен тоту (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам утларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү;

- Олы Елга авылы суүткәргеч магистраленең су задвижкаларын сатып алу, урнаштыру һәм алыштыру (шартнамә буенча эшкә түләүгә);
- авыл җирлеге торак пунктларындагы урам утларына энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга (шартнамә буенча эшкә түләүгә);
- Олы Елга авыл җирлеге торак пунктларында урамнарның юл өлешен кышын кардан тотуга (кардан чистартуга) (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә);
- Сасскан Тавы авылында контейнер мәйданчыгы ясау һәм төзекләндерү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Олы Елга авылында балалар мәйданчыгы төзү (инвентарь сатып алу, урнаштыру, шартнамә нигезендә эш хакы түләү);
- суэтем башнясын сатып алу, монтажлау һәм урнаштыру (килешү буенча эшләрне түләү);
- мотопомпа өчен янгын җиһазларе сатып алу.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 йорт; Сорочьи Горы авылы, Үзәк урам,16а йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы: Мингалеев И.Н.